**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 3 октябрь № 739

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 декабрь, 1097 нче карары белән расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 ел, 31 декабрь, 1097 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 10 июнь, 393 нче, 2014 ел, 6 декабрь, 955 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлектә:

1 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 нче таблица

Хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү буенча учреждениеләр (аерымланган бүлекчәләр) төркеменә бәйле рәвештә билгеләнә торган вазыйфаи окладлары

| Т/с | Хезмәткәрләрнең вазыйфалары | Учреждениеләр (аерымланган бүлекчәләр) төркемнәре буенча вазыйфаи оклад күләме, сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | I | II | III | IV |
| 1 | Учреждениеләр җитәкчеләре (башлыклары) | 23 063 | 17 987 | 16 701 | 15 568 |
| 2 | Учреждениедә идарә, хезмәт, штаб, үзәк башлыгы | 15 568 | 14 420 | 13 414 | 12 422 |
| 3 | Мөстәкыйль бүлек башлыгы | 14 420 | 13 414 | 12 422 | 11 499 |
| 4 | Учреждениедә идарә, хезмәт, штаб, үзәк составындагы бүлек; вәкиллекнең; мөстәкыйль бүлек (төркем) башлыгы | 13 414 | 12 422 | 11 499 | 10 492 |
| 5 | Бүлек составындагы бүлекчә (төркем) башлыгы | 12 422 | 11 499 | 10 492 | 9 568 |
| 6 | Эзләү-коткару отряды башлыгы | 25 371 | 19 790 | 18 356 | 17 135 |
| 7 | Янгынга каршы хезмәт отряды башлыгы | 16 701 | 15 568 | 14 420 | 13 414 |
| 8 | Янгынга каршы хезмәтнең янгын сүндерү часте, аерым посты башлыгы | 15 261 | 14 253 | 13 261 | 12 338 |
| 9 | Янгынга каршы хезмәт отряды буенча оператив кизү | 11 330 | 10 408 | 9 553 | 8 771 |
| 10 | Янгынга каршы хезмәтнең матди-техник тәэмин итү отряды башлыгы ярдәмчесе | 11 499 | 10 492 | 9 568 | 8 717 |
| 11 | Янгынга каршы хезмәтнең җитештерү-техник үзәге, янгынга каршы хезмәтнең уку-укыту үзәге башлыгы | 14 420 | 13 414 | 12 422 | 11 499»; |

2 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 нче таблица

Хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү буенча учреждениеләр (аерымланган бүлекчәләр) төркеменә бәйсез рәвештә билгеләнә торган вазыйфаи окладлары

| Т/с | Хезмәткәрләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Идарә пункты башлыгы | 10 492 |
| 2 | Учреждение составындагы идарә пункты башлыгы | 8 717 |
| 3 | Химия-радиометрия лабораториясе башлыгы | 10 492 |
| 4 | Уку-укыту-методика бүлмәсе мөдире | 10 492 |
| 5 | Учреждениенең оператив кизүе | 8 717 |
| 6 | Идарә пунктының оператив кизүе | 9 568 |
| 7 | Оператив кизү ярдәмчесе | 7 931 |
| 8 | Төп эшчәнлек буенча инспектор (өлкән инспектор): | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | инспектор | 7 931 |
| | өлкән инспектор | 9 568 |
| 9 | Коткаручы: | |
| | халыкара класслы коткаручы | 15 874 |
| | 1 класслы коткаручы | 14 757 |
| | 2 класслы коткаручы | 13 666 |
| | 3 класслы коткаручы | 12 659 |
| | коткаручы | 11 541 |
| 10 | Су астында эшләүче белгеч: | |
| | су астында эшләүче өлкән белгеч | 12 422 |
| | су астында эшләүче белгеч | 11 499 |
| 11 | Гражданнар оборонасы белгече (төп белгече): | |
| | гражданнар оборонасы төп белгече | 11 499 |
| | I категорияле ражданнар оборонасы белгече | 10 492 |
| | II категорияле гражданнар оборонасы белгече | 9 568 |
| | гражданнар оборонасы белгече | 8 717 |
| 12 | Янгынга каршы хезмәтнең янгын сүндерү часте каравылы, аерым посты башлыгы | 11 190 |
| 13 | Янгынга каршы хезмәтнең күчмә насос станциясе башлыгы | 8 717 |
| 14 | Янгынга каршы хезмәтнең күчмә газ-су белән янгын сүндерү җайланмасы башлыгы | 8 717 |
| 15 | Янгынга каршы хезмәтнең янгын сүндерү часте бүлекчәсе (аерым посты) командиры | 10 408 |
| 16 | Янгынга каршы хезмәтнең янгын сүндерү частенә караган газ-төтеннән яклау хезмәте мастеры | 9 568 |
| 17 | Янгын сүндерү часте (аерым посты) диспетчеры | 7 931 |
| 18 | Янгынга каршы хезмәт отряды (янгын сүндерү часте) инженеры: | |
| | төп инженер | 11 499 |
| | I категорияле инженер | 9 568 |
| | II категорияле инженер | 8 717 |
| | инженер | 7 931 |
| 19 | Янгынга каршы хезмәтнең янгынга каршы профилактика буенча инструкторы | 6 505 |
| 20 | Янгынга каршы хезмәтнең янгын сүндерүчесе*: | |
| | 1 класслы янгын сүндерүче | 10 435 |
| | 2 класслы янгын сүндерүче | 9 568 |
| | 3 класслы янгын сүндерүче | 8 786 |
| | янгын сүндерүче | 8 001 |
| 21 | Коткару станциясе башлыгы | 10 492 |
| 22 | Пост (коткару посты) башлыгы | 7 220 |
| 23 | Маневрлы эзләү төркеме башлыгы | 12 422 |
| 24 | Су асты, коткару судносы капитан-механигы | 7 931 |
| 25 | Патруль, коткару катеры капитаны (өлкән моторист-йөртүчесе) | 6 505 |

--------------------------------------------

*Янгын сүндерүчеләргә класслар бирү Учреждение төзегән квалификация комиссиясе тарафыннан һәм Учреждение җитәкчесе боерыгы белән расланган нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 нче таблица

Өстәмә белем бирү оешмалары укытучыларының
вазыйфаи окладлары

| Хезмәткәрләрнең вазыйфалары | Квалификация категорияләре буенча вазыйфаи оклад күләме, сум | | | |
|---|---|---|---|---|
| | югары | беренче | икенче | категориясез |
| Укытучы | 14 420 | 13 414 | 12 422 | 8 717»; |

4 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 нче таблица

Гомумтармак вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрнең
вазыйфаи окладлары

| Т/с | Хезмәткәрләрнең категорияләре һәм вазыйфалары | Вазыйфаи окладлар (сум) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | Җитәкчеләр | |
| 1 | Мөдирләр: | |
| | канцелярия: | |
| | документлар әйләнеше күләме елга 25 мең документка кадәр булганда | 5 864 |
| | документлар әйләнеше күләме елга 25 мең документтан артык булганда | 6 505 |
| 2 | Склад мөдире | 6 505 |
| 3 | Үзәк склад мөдире | 7 220 |
| 4 | Уку-укыту-методика бүлмәсе мөдире | 10 492 |
| 5 | Гараж башлыгы | 11 499 |
| 6 | Радиостанция башлыгы | 9 568 |
| | Белгечләр | |
| 7 | Китапханәче, библиограф: | |
| | төп | 11 499 |
| | беренче категорияле | 10 492 |
| | икенче категорияле | 8 717 |
| | категориясез | 7 220 |
| 8 | Бухгалтер: | |
| | төп бухгалтер | 11 499 |
| | I категорияле бухгалтер | 9 568 |
| | II категорияле бухгалтер | 7 931 |
| | бухгалтер | 6 505 |
| 9 | Бухгалтер-ревизор: | |
| | төп бухгалтер-ревизор | 11 499 |
| | I категорияле бухгалтер-ревизор | 9 568 |
| | II категорияле бухгалтер-ревизор | 8 717 |
| | бухгалтер-ревизор | 7 931 |
| 10 | Эзләү-коткару хезмәтенең гомуми практика табиблары | 11 499 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | Квалификация категориясе булганда: | |
| | икенче категория | 12 422 |
| | беренче категория | 13 414 |
| | югары категория | 14 420 |
| 11 | Баш белгеч (Учреждение бүлекләрендә, лабораторияләрендә, идарәләрендә, хезмәтләрендә, штабларында, үзәкләрендә) | 11 891 |
| 12 | Диспетчер (өлкән диспетчерны да кертеп): | |
| | өлкән диспетчер | 6 505 |
| | диспетчер | 5 864 |
| 13 | Документлар алып баручы: | |
| | документлар алып баручы төп белгеч | 11 499 |
| | документлар алып баручы I категорияле белгеч | 9 568 |
| | документлар алып баручы II категорияле белгеч | 8 717 |
| | документлар алып баручы | 7 220 |
| 14 | Инженер (барлык исемдәге): | |
| | төп инженер | 11 499 |
| | I категорияле инженер | 9 568 |
| | II категорияле инженер | 8 717 |
| | инженер | 7 220 |
| 15 | Инспекторлар: кадрлар буенча, кушкан эшләрнең үтәлешен тикшерү буенча (өлкән инспекторларны да кертеп): | |
| | өлкән инспектор | 6 505 |
| | инспектор | 5 864 |
| 16 | Корректор: | |
| | өлкән корректор | 8 717 |
| | корректор | 7 931 |
| 17 | Лаборант (өлкән лаборантны да кертеп): | |
| | өлкән лаборант | 6 505 |
| | лаборант | 5 864 |
| 18 | Механик | 7 220 – 11 499 |
| 19 | Тәрҗемәче: | |
| | төп тәрҗемәче | 11 499 |
| | I категорияле тәрҗемәче | 9 568 |
| | II категорияле тәрҗемәче | 8 717 |
| | тәрҗемәче | 7 220 |
| 20 | Программист: | |
| | төп программист | 13 414 |
| | I категорияле программист | 11 499 |
| | II категорияле программист | 9 568 |
| | программист | 7 931 |
| 21 | Психолог*: | |
| | төп психолог | 11 499 |
| | I категорияле психолог | 10 492 |
| | II категорияле психолог | 9 568 |
| | психолог | 8 717 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 22 | Кадрлар буенча белгеч | 7 931 |
| 23 | Техник: | |
| | I категорияле техник | 7 220 – 8 717 |
| | II категорияле техник | 6 505 |
| | техник | 5 864 |
| 24 | Эзләү-коткару хезмәте фельдшеры | 8 717 |
| | Түбәндәге квалификация категориясе булганда: | |
| | югары категорияле | 11 499 |
| | беренче категорияле | 10 492 |
| | икенче категорияле | 9 568 |
| 25 | Рәссам: | |
| | төп рәссам | 11 499 |
| | I категорияле рәссам | 9 568 |
| | II категорияле рәссам | 8 717 |
| | рәссам | 7 220 |
| 26 | Икътисадчы (барлык исемдәге): | |
| | төп икътисадчы | 11 499 |
| | I категорияле икътисадчы | 9 568 |
| | II категорияле икътисадчы | 8 717 |
| | икътисадчы | 7 220 |
| 27 | Юрисконсульт: | |
| | төп юрисконсульт | 11 499 |
| | I категорияле юрисконсульт | 9 568 |
| | II категорияле юрисконсульт | 8 717 |
| | юрисконсульт | 7 220 |
| | Техник башкаручылар | |
| 28 | Архивариус | 5 864 |
| 29 | Үткәрү бюросы кизүе | 5 331 |
| 30 | Кизү (белешмәләр бирү, зал, кунакханә каты, ял бүлмәсе, тулай торак һ.б. буенча) | 5 864 |
| 31 | Эш башкаручы | 5 596 |
| 32 | Кассир: | |
| | өлкән кассир | 5 864 |
| | кассир | 5 596 |
| 33 | Комендант | 6 505 |
| 34 | Тикшерү-үткәрү пункты контролеры | 5 864 |
| 35 | Секретарь | 5 596 |
| 36 | Секретарь-машинистка: | |
| | I категорияле секретарь-машинистка | 5 864 |
| | II категорияле секретарь-машинистка | 5 596 |
| 37 | Экспедитор | 5 331 |
| 38 | Йөк ташу буенча экспедитор | 5 596 |

-------------------------------------------

***** Гадәттән тыш хәлләр салган зыяннарны бетерү вакытында кичектергесез ярдәм күрсәтү мәсьәләләрен хәл итү өчен каралган махсус күчмә бүлекчәләр психологларының (биләгән вазыйфаларына бәйсез рәвештә) вазыйфаи окладлары 20 процентка арттырыла. Учреждениедә махсус күчмә бүлекчәләрнең булу-булмавы Учреждениенең штат расписаниесендә күрсәтелгән булырга тиеш.»;

5 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 нче таблица

Һөнәри эшчәнлекләрен эшчеләр вазыйфалары буенча гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең тариф ставкалары

| Тариф ставкалары төркемнәре | I | II | III | IV | V | VI | VII | VIII | IX |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Тариф ставкасы күләме, сум | 5 135 | 5 331 | 5 596 | 5 864 | 6 505 | 7 220 | 7 931 | 8 717 | 9 584 – 11 330». |

2. Бу карарның гамәле 2015 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\739.doc